ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 16 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Әлеге Законга кушымта нигезендә Спас муниципаль районы составына керә торган "Болгар шәһәре", "Приволжский авыл җирлеге" һәм "Өчкүл авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртергә.

**2 статья**


"Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 7 (II өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 11 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Спас муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 кушымта

## «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керә торган муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## <u>карта-схемасы</u>




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- 10 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | | |
|---|---|---|
| *9(3)-1(34)* | - | Тәтеш муниципаль районы |
| *1(34)-20(33)* | - | Кама Тамагы муниципаль районы |
| *20(33)-24(32)* | - | Лаеш муниципаль районы |
| *24(32)-25(31)* | - | Алексеевск муниципаль районы |
| *25(31)-40(2)* | - | Әлки муниципаль районы |
| *40(2)-9(3)* | - | Ульяновск өлкәсе |

"Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Болгар шәһәре |
| 2 | Аграмак авыл җирлеге |
| 3 | Антоновка авыл җирлеге |
| 4 | Бураково авыл җирлеге |
| 5 | Әҗмәр авыл җирлеге |
| 6 | Иске Рәҗәп авыл җирлеге |
| 7 | «КИМ» авыл җирлеге |
| 8 | Кызыл Бистә авыл җирлеге |
| 9 | Кузнечиха авыл җирлеге |
| 10 | Куралово авыл җирлеге |
| 11 | Никольский авыл җирлеге |
| 12 | Полянка авыл җирлеге |
| 13 | Приволжский авыл җирлеге |
| 14 | Урта Йорткүл авыл җирлеге |
| 15 | Өчкүл авыл җирлеге |
| 16 | Чәчәкле авыл җирлеге |
| 17 | Ямбакты авыл җирлеге |

";

2) 3 нче кушымтаның бишенче һәм алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Приволжский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньякка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча аның ярына кадәр 8,4 км уза, шушы яр буйлап көнчыгышка таба 550 м бара, алга таба "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 100 м, урман массивының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 40 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 250 м, дамбаның көнчыгыш чиге буйлап 700 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 150 м, "Базарлы Матак – Болгар" – Ржавец автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 550 м бара, шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап 600 м уза, шуннан соң, "Базарлы Матак – Болгар" – Ржавец автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм профильле автомобиль юлы полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 250 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап 150 м бара, аннары, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр 750 м уза, шушы яр буйлап көнчыгышка таба 650 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, сазланган ярны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка, көньякка таба

25 м, сынык сызык ясап, 54 нче, 61 нче нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 600 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 550 м уза, урман массивының көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, 61 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 50 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м бара, аннары, сынык сызык ясап, "Базарлы Матак – Болгар" – Ржавец автомобиль юлы буйлап көнчыгышка таба 2,4 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 900 м, көньяк-көнчыгышка таба 400 м, көньяк-көнбатышка таба 800 м, көнбатышка таба 600 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 850 м һәм көньяк-көнбатышка таба 1,0 км уза, аннары урман полосасының төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 200 м һәм, сынык сызык ясап, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 200 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 300 м, инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 200 м, көньяк-көнбатышка таба 1,0 км уза, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 200 м бара, шуннан соң урман утыртмаларының төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 200 м, төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 500 м һәм көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 300 м уза, аннары, сынык сызык ясап, урман полосаларын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 150 м бара, шуннан соң урман полосасының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 200 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 150 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 650 м "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге, Приволжский һәм Өчкүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Өчкүл авылыннан 3,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Өчкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка таба 1,0 км, производство объектының көньяк чиге буйлап 300 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап Болгар – Танкеевка автомобиль юлына кадәр 550 м уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 800 м бара, аннары, шушы автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка таба 350 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 29 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,8 км һәм 28 нче урман кварталы буенча 1,3 км бара, аннары 28 нче, 21 нче нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 2,3 км уза, шуннан соң 14, 13, 12 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр 3,1 км бара, сусаклагыч акваториясе буйлап 2,0 км 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

3) 16 нчы кушымтаның бишенче һәм алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Приволжский авыл җирлеге чиге Өчкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,4 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 2,0 км, төньяк-көнбатышка таба урман полосасына кадәр 250 м бара, әлеге урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 900 м Приволжский, Өчкүл авыл җирлекләре һәм "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Өчкүл авылыннан 3,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Приволжский авыл җирлеге чиге "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньякка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча аның ярына кадәр 8,4 км уза, шушы яр буйлап көнчыгышка таба 550 м бара, алга таба "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 100 м, урман массивының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 40 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 250 м, дамбаның көнчыгыш чиге буйлап 700 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 150 м, "Базарлы Матак – Болгар" – Ржавец автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 550 м бара, шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап 600 м уза, шуннан соң, "Базарлы Матак – Болгар" – Ржавец автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм профильле автомобиль юлы полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 250 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап 150 м бара, аннары, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр 750 м уза, шушы яр буйлап көнчыгышка таба 650 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, сазланган ярны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка, көньякка таба 25 м, сынык сызык ясап, 54 нче, 61 нче нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 600 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 550 м уза, урман массивының көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, 61 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 50 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м бара, аннары, сынык сызык ясап, "Базарлы Матак – Болгар" – Ржавец автомобиль юлы буйлап көнчыгышка таба 2,4 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 900 м, көньяк-көнчыгышка таба 400 м, көньяк-көнбатышка таба 800 м, көнбатышка таба 600 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 850 м һәм көньяк-көнбатышка таба 1,0 км уза, аннары урман полосасының төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 200 м һәм, сынык сызык ясап, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 200 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 300 м, инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 200 м, көньяк-көнбатышка таба 1,0 км уза, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 200 м бара, шуннан соң урман утыртмаларының төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 200 м, төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 500 м һәм көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 300 м уза, аннары, сынык сызык ясап, урман полосаларын кисеп үтеп, көньяк-

көнбатышка таба 150 м бара, шуннан соң урман полосасының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 200 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 150 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 650 м 3 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

4) 18 нче кушымтаның дүртенче һәм бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Өчкүл авыл җирлеге чиге "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Өчкүл авыл җирлеге, "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге һәм Приволжский авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Өчкүл авылыннан 3,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка таба 1,0 км, производство объектының көньяк чиге буйлап 300 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап Болгар – Танкеевка автомобиль юлына кадәр 550 м уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 800 м бара, аннары, шушы автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка таба 350 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 29 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,8 км һәм 28 нче урман кварталы буенча 1,3 км бара, аннары 28 нче, 21 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 2,3 км уза, шуннан соң 14, 13, 12 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр 3,1 км бара, сусаклагыч акваториясе буйлап 2,0 км 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Өчкүл авыл җирлеге чиге Приволжский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Өчкүл, Приволжский һәм Кызыл Бистә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Вал авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,4 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 2,0 км, төньяк-көнбатышка таба урман полосасына кадәр 250 м бара, әлеге урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 900 м 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.".

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.


Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 01 март
№ 9-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Үзгәрешләрне исәпкә алып,
муниципаль берәмлекләр чикләренең
карта-схемасы

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта




Шартлы билгеләр

- Спас муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре

А-Б - «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең һәм Өчкүл авыл жирлегенең чиктәш чиге

Б-В - «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең һәм Приволжский авыл жирлегенең чиктәш чиге

- жирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар

I - Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Спас муниципаль районының Приволжский авыл жирлеге территориясе

II- Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Спас муниципаль районының Өчкүл авыл жирлеге территориясе